**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_22.03.2021_ **М ө с л и м** № _124__

**Дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр өчен түләүсез туклануны оештыру турында нигезләмәне раслау хакында**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү максатыннан, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру өчен Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр өчен түләүсез туклануны оештыру турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 01 апреленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Демидов Р.Т.**

_______ ел, ___ номерлы карарга
1 номерлы кушымта

**Дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр өчен түләүсез туклануны оештыру турындагы нигезләмә.**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучы балалары булган гаиләләргә адреслы, максатчан социаль ярдәм күрсәтү максатларында эшләнде һәм күп балалы аз керемле гаиләләрдән 5-11 сыйныф укучыларын түләүсез бер мәртәбә туклануны оештыру шартларын билгели.

1.2. Бер тапкыр туклану (төшке аш) хокукын бирү өчен төп критерий булып тора:

* Үз составында дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган, гариза биргән көнгә 18 яшь тулмаган күп балалы гаиләләрдәге балалар.

1.3. Үз составында дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган, урта гомуми белем бирү учреждениеләрендә («Мөслим гимназиясе» МБББУ, «Мөслим лицее» МБББУ, «Г. Тукай исемендәге Мөслим урта мәктәбе» МБББУ, «Михайловка урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ «Тат. Бүләр урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ, «Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ) укучы балалар өчен 15 (унбиш) сумлык ата-ана түләвеннән торган иртәнге аш һәм 28 (егерме сигез) сумлык «2020 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары нигезендә бирелә торган 8 (сигез) сум һәм Мөслим муниципаль районы бюджетыннан 20 (егерме) сум субсидия исәбеннән түләүсез кайнар төшке ашлар оештырыла.

Үз составында дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган, төп гомуми белем бирү учреждениеләрендә («М.Бүләр төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Тойгелде төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Әмәкәй төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Баек төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Түбән Табын төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Тат. Шуран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Яңа Усы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Рус Шуган төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Баланлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Салауз Мухан төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «Олы Чакмак төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ) укучы балалар өчен 28 (егерме сигез) сумлык «2020 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары нигезендә бирелә торган 8 (сигез) сум һәм Мөслим муниципаль районы бюджетыннан 20 (егерме) сум субсидия исәбеннән түләүсез кайнар төшке ашлар оештырыла.

## II. Түләүсез туклану бирү тәртибе

2.1. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе ата-аналарга күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чарасы: бушлай бер мәртәбә туклануга хокук турында хәбәр итә.

2.2. Ташламалы категориядәге гаиләдә укучы баланың ата-анасы (законлы вәкиле) түләүсез туклану белән тәэмин итү хокукын алу өчен гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе исеменә түбәндәге документлар бирә:

- язма рәвештә гариза (нигезләмәгә 1 нче кушымта);
- күп балалы гаилә таныклыгы күчермәсе;
- туу турында барлык балаларның таныклык күчермәсе.

2.1 Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризалары һәм тиешле документлар пакеты гомуми белем бирү учреждениесе администрациясе тарафыннан карала. Гомуми белем бирү учреждениесенең коллегиаль органы карары нигезендә туклануга ташламалар бирү турында мәктәп директоры боерыгы рәсмиләштерелә.

2.2 Гомуми белем бирү учреждениесе түләүсез бер тапкыр туклану хокукына ия булган барлык балаларны исәпләүне (туган даталары белән) алып бара

2.3. Ташламалы категориягә кертелгән укучылар исемлеге елга 2 тапкыр яңадан карала: сентябрьдә 30 кадәр, гыйнварда 30 числога кадәр.

2.4. 30 сентябрьдән соң килгән гаризалар киләсе елның гыйнвар аенда, 30 гыйнвардан соң килгән гаризалар киләсе уку елының сентябрендә карала.

2.5. Укучыларны туклandыручы затка һәм мәктәп администрациясенә туклануны оештыру һәм аның сыйфаты өчен җаваплылык йөкләнә.

2.6. Боерыкларның күчермәләре «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУга 2021 елның 26 мартыннан да соңга калмыйча, киләсе уку елында 30 сентябрьгә, 30 гыйнварга кадәр бирелә.

2.7. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ түләүсез туклану белән тәэмин итү хокукын алган укучыларның гомуми исемлеген формалаштыра.

2.8. Түләүсез туклану белән тәэмин итү хокукын алганнар исемлегенә кертелгәннән соң, документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла.

2.9. Исемлек билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен үзәкләштерелгән бухгалтерия бирелә.

2.10. Түләүсез туклануга мохтаҗ «ташламалы категория»не билгеләү өчен мәктәп җаваплы.

2.11. Бирелә торган документларның дөреслеге өчен баласына түләүсез туклану хокукын бирүне сорап гариза язучы ата-аналар (законлы вәкилләр) җаваплы.

2.12. Балаларны матди карап тотуга күп балалы гаиләләргә, опекуннарга (попечительләргә) ай саен акча түләнсә, түләүсез туклануга хокук әлеге укучыларга бирелми.

Дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган
күп балалы гаиләләр өчен түләүсез туклануны
оештыру турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

________________________МББУ директоры

________________________________________
________________(гариза бирүченең Ф.И.А.и.)
Адрес ______________________________
____________________________________

гариза.

Күп балалы аз тәэмин ителгән гаилә әгъзасы булган _____ сыйныф укучысы __________________________________________ (Ф.И.А.и.) ______________МББУ ашханәсендә уку көнендә бер тапкыр бушлай туклану хокукын бирүегезне сорыйм.

____________ елдан ___________ кадәр гамәлдә булган _____ номерлы таныклык.

Гаризага түбәндәге документлар пакетын терким:

- күп балалы гаилә таныклыгы күчермәсе;
- туу турында барлык балаларның таныклык күчермәсе.

Имза
Дата